

# Әнием, мин сине көтәм!!!

11 нче сыйныфта Гөлзада Әхтәмованың “Берсе ак, берсе чуар” хикәясен укып, фикер алышу.



**Авторы II категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Закирова Айсылу Юныс кызы.**

**Табар-Черкен урта мәктәбе**

# Дәрес планы

- Педагогик оештыру
- Иҗади эшләр
- Яңа төшенчәләр һәм күнекмәләр формалаштыру
- Сораулар
- Кабатлау, тикшерү
- Гомумиләштерееп нәтиҗә ясау
- Өйгә эш бирү
- Йомгаклау

# Дәреснең төп максатлары

**-Татар язучылары иҗатында ятим бала образын ачу;**

**-Укучыларның иҗади эшчәнлеген үстерү;**

**-Әниләргә, гаиләгә карата хөрмәт хисе тәрбияләү һәм җәмгыятьтә, гаиләдә Ана - бала образы ачу;**



Чү,тынып кал, тормыш!
Шауламагыз, кошлар!
Агымсулар, сез дә туктагыз!
Әкрен генә искән, сез дә, җилләр
Зинһар, тынычлыкны бозмагыз!

Ишетәсезме, берәү елый анда?
Ялгыз калып түгә яшьләрен.
Үкенә дә кебек ни өчендер,
Әллә сагына үткән көннәрен.

# Гөлзада Әхтәмованың“Берсе ак, берсе чуар” хикәясен укып, фикер алышу.

- ***Эчтәлек белән танышу.***
- ***Төркемнәрдә тәрҗемә эшен башкару.***
- ***Бирелгән сүзләрне дөрес укып, истә калдыру.***

# Бирелгән сүзләрне уку, истә калдыру

- [чуар] пестрый
- [к,упшы] нарядный
- [к,ызарта] красит в красный цвет
- [тапшырган] сдавала
- [тырнак,лары] ногти
- [сагалый] подстерегает
- [ыңгыраша ] стонет
- [тамчы] капля
- [тилмэргән] мучилась
- [чэбеш] цыпленок

# Тексттан фразеологизмнарны табып, мәгънәсен аңлату.

- Кәеф-сафа кору –

наслаждаться, жить в своё удовольствие
- Җил-яңгыр тидермәү –

не давать в обиду
- Бар дип тә белмәү –

ни в грош не ставить

# *Ак тавык:*

- Купшы
- Чибәр
- Тырнакларын буяган
- Кикрикләрен кызарткан
- Йомыркаларын инкубаторга тапшырган
- Кәеф-сафа корып яшәгән





# Чуар тавык





-бер оя йомырка салган
-чебиләр чыгарган
-җим табып, аларны ашаткан
-җил-яңгырдан саклаган
-чебиләрен яшәргә өйрәткән





# Чуар тавык-бәхетле ана. Анын турында балалары кайгырта.

-Әнием, менә сиңа тәмле су!

-Әнием, менә бу даруны эч эле.

-Әнием, менә сиңа кура җиләкле, мәтрүшкәле чәй.

-Әнием, менә сиңа җылы сөт!





# Кичер мине, балам.

-Ак тавык бер чеби дә үстермәгәненә бик үкенгән.

-Ыңгырашып, кемнәндер ярдәм көтеп ята.



# Сораулар:

- Хикәянең төп темасы нинди?
- Автор ак тавык образы аша нәрсә әйтергә теләгән?
- Нәниләрен бала тудыру йортында калдырган яшь аналар турында сез нәрсә әйтә аласыз?
- Тормыш авырлыклары аларның бу адымына сәбәп була аламы?
- Бүгенге көндә нинди изге эшләр эшләнә?
- Мисаллар китерә аласызмы?

# Биремнәр.

Тәрҗемә итегез.

Допустим, ваша мама больна:

-спросите, нет ли у неё температуры;

-спросите, какая у неё температура, нужно ли ей лекарство;

-предложите ей лекарство;

-предложите чай с мёдом;

-убедите её в том, что надо полежать.

# Əхлак дəреслəре

**“Балалар белəн ата-аналары арасындагы үзара мөнəсəбəтлəр балаларга ата-аналарына карата зур җаваплылык өсти. Үзлəренə карата зур кайгыртучанлыкка, түземлелеккə, яхшы мөгалəмəгə һəм тəрбиягə ата-анадан да лаек беркем юк.”**

Риза Фəхреддин.

# Әхлак дәресләре

- “Әти-әнисе картайгач, алар турында кайгырту, аларны үз өендә яшәтү балаларның бурычы булып тора. Картлар йортына җибәреп, алардан котылырга тырышу-әдәпсезлек кенә түгел, ә бәлки оятсызлык та”. Риза Фәхреддин

# Ана- шәфкать дингезе

- “Ата-анагызга игелек итегез, сезгә дә балаларыгыз игелек итәр”. Хәдис.
- Ата-ана теләге утка-суга батырмас. Мәкаль
- Ачтан үлсәң дә ата-ананңны ташлама. Мәкаль

# Ана-бөек исем.


- “И газиз балалар! Ата-аналарыгыз сезгә иң авыр хезмәтләрне кылдылар, һәрвакыт сезнең өчен тырыштылар. Инде сез дә аларның бу яхшылыкларын камил кылып кайтарыгыз, күчегездән килгәнчә аларга чын күңелдән хезмәт итегез, хөрмәт күрсәтегез!”

# Әсәрнең әһәмияте:

-аналык бурычын үтәү;

-әти-әниләрне хөрмәт итәргә;

-кешелекле булырга;



# ***Үкенү тулы хисләр ташкыны***

Менә калдым ялгыз, нишләргә соң миңа?

Яшәвемнең яме югалды.

Туктады күк тормыш шул минутта

Караңгылык басты юлымны.



# Әни----------------ем!!!

Тик шуны бел, әнием, гомерем буе

Онытмамын сине, ышан тик.

Мин яратам сине өзелеп-өзелеп,

Бер күрермен диеп ышанып.

Күрешербез диеп ышанып.



# Без бергә булырга тиеш!!!

